| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2023 г. Казань № 391-13/э-2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 №3-4/э карары белән «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә билгеләнгән озак сроклы индивидуаль тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.11.2022 №315-14/э-2022 карарын гамәлдән чыккан дип тану турында

Татарстан Республикасы Югары Судының 31.03.2023 №3а-176/2023 карарын, Гомуми юрисдикциядәге дүртенче апелляция судының 04.09.2023 №66а-1147/2023 билгеләмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 24.11.2023 №50-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2024 елларга «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә индивидуаль тарифлар билгеләү турында» 11.12.2019 №3-4/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2020 №443-15/э-2020, 08.12.2021 №459-22/э-2021, 16.12.2021 №635-27/э-2021, 11.11.2022 №315-14/э-2022 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча

дәүләт комитетының 11.12.2019 №3-4/э карары белән билгеләнгән озак сроклы индивидуаль тарифларга 2021 ел өчен үзгәреш кертү хакында» 11.11.2022 №315-14/э-2022 карарын гамәлдән чыккан дип таныргa.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча
башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 №3-4/э
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2023 № 391-13/э-2023
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы территориясендә «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2020 | 253 741,29 | 119,70 | 0,57789 | 253 741,29 | 119,70 | 0,57789 |
| | | 2021 | 172 079,53 | 132,24 | 0,44297 | 172 079,53 | 132,24 | 0,44297 |
| | | 2022 | 131 870,60 | 168,02 | 0,40651 | 131 870,60 | 168,02 | 0,40651 |
| | | 2023 | 184 743,99 | 187,11 | 0,52017 | 184 743,99 | 187,11 | 0,52017 |
| | | 2024 | 265 543,96 | 130,80 | 0,61784 | 318 564,13 | 134,72 | 0,62176 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 №3-4/э
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2023 № 391-13/э-2023
карары редакциясендә)

«ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2020-2024 елларга кирәкле тулай кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы (югалтуларны исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | "ТранзитЭнергоМонтаж" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2020 | 44 059,64 |
| | | 2021 | 29 879,89 |
| | | 2022 | 23 592,94 |
| | | 2023 | 38 681,70 |
| | | 2024 | 46 833,59 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге